# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

№1 12.11.2019

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге составына керүче
Дүсем авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2020 елда үзара салым кертүгә сез балигъ булган һәр кешедән 250,00 (ике йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча 2019 елның 12 ноябрендә Дүсем авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү-Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән (I төркем инвалидларыннан , вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге уку йортлары студентларыннан тыш). Алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү турында

Карар кабул ителде:

- Дүсем авылының урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру ;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Дусем авылының җирле әһәмияттәге юлларны кышын кардан чистарту;
- Дүсем авылында чаралар (Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Дүсем авылының зияратын эйләндереп алу өчен материаллар сатып алу һәм хезмәт хакы түләү.

ӘЙЕ ЮК?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 180 кеше кергән, җыенда катнашучылар саны 151 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 151 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Сарман муниципаль районы составына керүче Ләшәү Тамак авыл җирлегенә караган Дүсем авылында узган халык җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (I төркем инвалидларыннан , вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш) 2020 елда 250,00 (ике йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне эшләүгә тотылуга килешәсезме?:
- Дүсем авылының урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру ;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Дусем авылының җирле әһәмияттәге юлларны кышын кардан чистарту;
- Дүсем авылында чаралар (Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Дүсем авылының зияратын әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу һәм хезмәт хакы түләү- кабул ителгән.
3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә һәм Ләшәү Тамак авылы, Яшьләр урамы, 1а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү-Тамак авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И.З.Хабибуллин